Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Юган поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

26 октябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 26 октбрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Юган поселогында теркәлгән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- кышкы чорда Юган бистәсендәге юлларны кардан чистартып тору;

- урам баганаларында лампаларны сатып алу һәм алыштыру» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 10 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 9 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 8 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге Юган поселогы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Юган поселогында теркәлгән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- кышкы чорда Юган бистәсендәге юлларны кардан чистартып тору;

- урам баганаларында лампаларны сатып алу һәм алыштыру мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге Юган поселогы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Т.В. Забойдулина

Заречный авыл җирлеге башлыгы Т.В. Забойдулина